ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24 апрель 2018 ел № 2265

Башкарма комитетның «Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына уллыкка (кызлыкка) алучы булу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү һәм уллыкка (кызлыкка) алырга кандидат буларак исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 2 октябрендәге 5944 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә тәрбиягә урнаштыру мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе Хөкүмәтенең аерым актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 30 декабрендәге 1716 нчы карары, шәһәр Уставының 42 маддәсе, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына уллыкка (кызлыкка) алучы булу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү һәм уллыкка (кызлыкка) алырга кандидат буларак исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 2 октябрендәге 5944 нче карарына (Башкарма комитетның 2017 елның 3 октябрендәге 5902 нче карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә.

1) преамбуладагы «2013 елның 9 апрелендәге 2393 нче» сүзләрен «2016 елның 13 маендагы 2363 нче» сүзләренә алмаштырырга;

2) Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына уллыкка (кызлыкка) алучы булу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү һәм уллыкка (кызлыкка) алырга кандидат буларак исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

- 1.4 пунктның 13 абзацындагы «2007 елның 19 февралендәге 150 нче» сүзләрен «2014 елның 11 мартындагы 147-р санлы» сүзләренә алмаштырырга;

- 2.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләрне күрсәтү өчен, закон яки башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, гариза бирүче тапшырырга тиешле документларның тулы исемлеге | Уллыкка (кызлыкка) бала алырга теләүче Россия Федерациясе гражданнары, уллыкка (кызлыкка) алучы булу мөмкинлеге турында бәяләмә бирүне үтенеп, Бүлеккә гариза (алга таба – гариза) бирәләр, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:<br>1) уллыкка (кызлыкка) бала алырга теләүче гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);<br>2) уллыкка (кызлыкка) бала алырга теләүче гражданның шәхесен таныклаучы документлар турында мәгълүматлар;<br>3) уллыкка (кызлыкка) бала алырга теләүче гражданның яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында мәгълүматлар;<br>4) гражданның Россия Федерациясе Гаилә кодексының 127 маддәсенең 1 пунктының 9-11 пунктчаларында күрсәтелгән хәлләре булмавын раслаучы мәгълүматлар;<br>5) ала торган пенсия, аның төре һәм күләме турында мәгълүматлар (керемнәренең төп чыганакларын мәҗбүри пенсия иминияте буенча иминият тәэминаты яки башка пенсия түләүләре тәшкил иткән затлар өчен).<br>Уллыкка (кызлыкка) бала алырга теләүче гражданнар гариза бирү датасын куеп, үз имзалары белән анда күрсәтелгән мәгълүматларны, шулай ук Россия Федерациясе законнары нигезендә, дөрес булмаган яисә хаталы мәгълүматлар биргән өчен җаваплылык турында хәбәрдар булуын раслыйлар.<br>Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:<br>1) уллыкка (кызлыкка) бала алырга теләүче затның кыскача автобиографиясе;<br>2) уллыкка (кызлыкка) бала алырга теләүче затның эш урыныннан вазыйфасы һәм соңгы 12 ай өчен уртача хезмәт хакының күләме күрсәтелгән белешмә һәм (яки) күрсәтелгән затның керемен раслаучы башка документ яки уллыкка (кызлыкка) бала алырга теләүче затның иренең (хатынының) эш урыныннан вазыйфасы һәм соңгы 12 ай өчен уртача хезмәт хакының күләме күрсәтелгән белешмә һәм (яки) күрсәтелгән затның иренең (хатынының) керемен раслаучы башка документ;<br>3) Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау | РФ Хөкүмәтенең 275 нче карары |

| | | |
|---|---|---|
| | министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны уллыкка (кызлыкка), опекага (попечительлеккә), тәрбиягә алучы гаиләгә яки патронат гаиләгә алырга ниятләгән гражданнарны медицина тикшерүе нәтиҗәләре турында бәяләмә;<br>4) язылышу турында таныклык күчермәсе (уллыкка (кызлыкка) бала алырга теләүче гражданнар никахта торган очракта);<br>5) Россия Федерациясе Гаилә кодексының 127 маддәсенең 6 пунктында билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе территориясендә ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә кабул итәргә теләүче затларның әзерлек үтүе турында таныклык күчермәсе (баланың якын туганнарыннан, уллыкка (кызлыкка) алучы булып торучы яки булып торган һәм уллыкка (кызлыкка) алу гамәлдән чыгарылмаган затлардан һәм балаларның опекуны (попечителе) булып торучы яки булып торган һәм аларга йөкләнгән бурычларны үтәүдән читләштерелмәгән затлардан тыш). Күрсәтелгән таныклык формасы Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан раслана.<br>Әлеге пунктның 2 пунктчасында күрсәтелгән документлар бирелгән көннән башлап бер ел дәвамында яраклы, әлеге пунктның 3 пунктчасында күрсәтелгән документлар бирелгән көннән башлап алты ай дәвамында яраклы.<br>Бүлеккә шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, граждан гариза биргәндә паспортын яки шәхесен раслаучы башка документын күрсәтергә тиеш.<br>Граждан тарафыннан 4, 5 пунктчаларда күрсәтелгән документларның күчермәләре тапшырылмаган очракта, Бүлек күрсәтелгән документларның күчермәләрен үзе әзерли (граждан тарафыннан тапшырылган әлеге документларның төп нөсхәләре булган очракта); | |

- 2.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге | Гариза бирелгән көннән башлап 2 эш көне эчендә Бүлек, тиешле вәкаләтле органнарның 2.5 пунктның 4-6 пунктчалары нигезендә граждfestival тарафыннан гаризада күрсәтелгән мәгълүматларны раславын сорый.<br>Ведомствоара запрос, бердәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасыннан һәм аңа тоташтырыла торган региональ ведомствоара электрон хезмәттәшлек системаларыннан файдаланып, электрон документ рәвешендә җибәрелә; | РФ Хөкүмәтенең 275 нче карары |

- 2.9 пунктның 10 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10) авыр яки аеруча авыр җинаятьләргә керә торган, шәхеснең гомеренә һәм сәламәтлегенә каршы, ирегенә, намусына һәм абруена каршы (законсыз рәвештә психиатрия стационарына урнаштырудан, яла ягу һәм рәнҗетүдән тыш), гаиләгә һәм балигъ булмаганнарга каршы, халык сәламәтлегенә һәм иҗтимагый әхлаклылыкка каршы, шулай ук җәмәгать иминлегенә, тынычлыкка һәм кешелек иминлегенә каршы җинаятьләр өчен хөкемгә тартылган булган яисә җинаять эзәрлекләвенә дучар булган затлар (реабилитацияләү нигезләре буенча җинаять эзәрлекләве туктатылган затлардан тыш);»;

- 3.5.1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.1. Гражданнарның уллыкка (кызлыкка) алучы булу мөмкинлеге турында бәяләмә әзерләү максатында, Бүлек белгече уллыкка (кызлыкка) бала алырга теләүче затларның тормыш шартларын тикшерүне үткәрә, анын барышында Россия Федерациясе Гаилә кодексында билгеләнгән, уллыкка (кызлыкка) бала алуга каршылык тудыра торган хәлләр булмау билгеләнә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар тиешле вәкаләтле органнар тарафыннан мәгълүматлар расланган көннән башлап 3 эш көне эчендә гамәлгә ашырылалар.»;

- 3.5.3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.3. Тиешле вәкаләтле органнарның гражданнар тарафыннан гаризага теркәлгән мәгълүматларны, документларны һәм тикшерү актын раслаучы фактлары нигезендә, Бүлек белгече гражданның уллыкка (кызлыкка) алырга кандидат булу мөмкинлеге турында бәяләмә яки кире кагу турында хат әзерли һәм имзалау өчен Бүлек башлыгына җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар 3.4.2 һәм 3.5.2 пунктчаларда каралган процедуралар тәмамланган вакыттан башлап ун эш көне эчендә гамәлгә ашырылалар.

Процедуралар нәтиҗәсе: әзерләнгән бәяләмә (4 нче кушымта) яки 3.5.6. пунктка туры китереп әзерләнгән, имзалау өчен Бүлек башлыгына җибәрелгән кире кагу турындагы хат.».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы

И.С. Зуев